МЭР ГОРОДА
НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
ХАКИМЕ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

24 август 2020ел № М 299

Шәһәр Хакименең аерым карарлары
үз көчен югалтуын тану турында

«Коррупциягә каршы тору турында Россия Федерациясе законнарын камилләштерү максатында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 16 декабрендәге 432-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясы, Татарстан Республикасының «Коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә аерым категория вазыйфаи затларның катнашу тәртибен камилләштерү өлешендә Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 7 маендагы 20-ТРЗ номерлы Законы, шәһәр Уставының 53 статьясы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.21, 5.22 пунктлары нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М :

1. Шәһәр Хакименең түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

1) «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленең рөхсәтен алу тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 11 августындагы М 327 номерлы;

2) «Шәһәр Хакименең «Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге муниципаль хезмәткәрләре тарафыннан бер генә кеше идарә итә торган башкарма орган сыйфатында коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән тыш) белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга яки аларның коллегиаль идарә органнары составына керүгә эшкә алучы (эш бирүче) вәкиленең рөхсәтен алу тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында»

2017 елның 11 августындагы М 327 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 24 апрелендәге М 167 номерлы.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны муниципаль берәмлек Башлыгы урынбасары Ф.И. Андреевага, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка, Контроль-хисап палатасы Рәисе Т.В. Шливега йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев